Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыены карары

2025 елның 29 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Керкәле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, 2025 елның 29 ноябрендә узган «Сез Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, балачактан инвалидлардан, шулай ук I төркем инвалидлардан, көндезге формада укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарыннан; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннарының тол хатыннарыннан тыш, 2026 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (триммер һәм бензопила өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу (Керкәле авылы территориясендә карт агачларны кисү һәм үлән чабу өчен); МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (дизель ягулыгы, май, фильтр сатып алу); тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү (коры-сары һәм чүп үләннәреннән территорияләрне чаптыру)Керкәле авылы территориясендә үлән чабу, полосаларны минераль ләштерү һәм сөрү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Керкәле авылы юлларын кардан чистарту);

3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Керкәле авылының Изгеләр чишмәсен төзекләндерү)соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә:

Җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 457 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 241 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «РИЗА» позициясе өчен гражданнар җыенында 241 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 0 катнашучы тавыш бирде.

Югарыда бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «Сез Лениногорск муниципаль районы Керкәле авыл җирлегенең Керкәле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидлар; Бөек Ватан сугышы һәм сугышчан хәрәкәтләр ветераннары; көндезге бүлектә белем алучы студентлардан тыш, 2025 елда 500 (Биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризамы:

1) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (триммер һәм бензопила өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу (Керкәле авылы территориясендә карт агачларны кисү һәм үлән чабу өчен); МТЗ-82.1 тракторын тоту һәм аңа хезмәт күрсәтү (дизель ягулыгы, май, фильтр сатып алу); тракторчы хезмәтләре өчен килешү буенча түләү (коры-сары һәм чүп үләннәреннән территорияләрне чаптыру)Керкәле авылы территориясендә үлән чабу, полосаларны минераль ләштерү һәм сөрү);

2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Керкәле авылы юлларын кардан чистарту);

3) җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү (Керкәле авылының Изгеләр чишмәсен төзекләндерү)соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң ун көн эчендә түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Керкәле ав., Совет ур., 95 йорт буенча административ бинада, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Лениногорск муниципаль районының
Керкәле авыл җирлеге башлыгы Л.И.Бигманов